ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 елның 26 маендагы | № 13

### Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-ФАП территориясе;
-мәктәп һәм балалар бакчасы территориясе;
-авыл мәдәният йорты территориясе;
-парк территориясе;
-балалар уен һәм спорт мәйданчыгы территориясе;
-мәчет территориясе;
- кибет территориясе;
-зиратлар территориясе;
-Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган мемориаль комплекс территориясе.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башлыгы Исмәгыйлев Фәнил Фәрит улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы, 53 йорт янында;

- Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы, 68 йорт янында;

- Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Өргәнче авылы, Яңа урамы, 5 йорт янында.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов